**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

15.07.2017

№ 445

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры Габделганиев Фәрит Солтан улына түбәндәге эшләрне:

Россия Федерациясе субъектларының су объектларын файдалану һәм саклау өлкәсендә дәүләт программаларын (дәүләт программаларына ярдәмче программаларны) әлеге дәүләт программаларын (дәүләт программаларына ярдәмче программаларны) бергәләп финанслауга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 19 апрелендәге 350 номерлы карары белән расланган «2012 – 2020 елларда Россия Федерациясенең су хуҗалыгы комплексын үстерү» федераль максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында субсидияләр бирү өчен сайлап алуны;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 326 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең 2012 – 2020 елларга «Әйләнә-тирә мохитне саклау» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына калдыклар белән эш итү һәм тупланган экологик зыянны бетерү өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү өчен Россия Федерациясе субъектларын сайлап алуны башкарганда Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгында һәм Федераль су ресурслары агентлыгында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә гамәл кылу, шул исәптән кирәкле документларга кул кую вәкаләте бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ